**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне камилләштерү максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2023 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-240 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 3 маендагы ПУ-347 номерлы һәм 2021 елның 13 декабрендәге ПУ-944 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар биләүче Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-243 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру

турында» 2022 елның 19 августындагы ПУ-576 номерлы Указы нигезендә билгеләнгән вазыйфаи окладлары (алга таба – хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары) күләмен арттырырга.

2. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын исәпләгәндә, әлеге Указның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте территориаль органы җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладын күләмен 1,061 тапкыр индексацияләргә һәм ул 12 688 сум тәшкил итәчәк.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының Вәкаләтле вәкиллеге эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2006 елның 25 августындагы ПУ-320 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2021 елның 13 декабрендәге ПУ-944 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), 4 пунктның өченче абзацында «сәгатьлек тариф ставкасының җиде проценты» сүзләрен «, хезмәт турындагы законнар нигезендә билгеләнгән» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-240 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 3 маендагы ПУ-347 номерлы һәм 2021 елның 13 декабрендәге ПУ-944 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктның 3 пунктчасында «ике процент» сүзләрен «15 процент» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктның 6 пунктчасындагы өченче абзацта «сәгатьлек тариф ставкасының җиде проценты» сүзләрен «, хезмәт турындагы законнар нигезендә билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

в) 6 пунктның 4 пунктчасында «ике процент» сүзләрен «15 процент» сүзләренә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренә элек чыгарылган актларын әлеге Указга туры китерергә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә, шулай ук аны үтәүне тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

7. Әлеге Указ 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 23 сентябрь
№ ПУ-665